ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

1311.2024 г.Казань № 314-2/э-2024

2025-2029 елларга «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә индивидуаль тарифлар билгеләү турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2024 елның 13 ноябрендәге 25-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә 2025-2029 елларга «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2025 елның 1 гыйнварыннан 2029 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә үзенә карата электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген

дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе өчен 2025-2025 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары билгеләргә.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясенең 2025-2029 елларга кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.11.2024 № 314-2/э-2024
карарына 1 нче кушымта

2025 елның 1 гыйнварыннан башлап 2029 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «РЖД» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «РЖД» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2025 | 287 680,83 | 88,38 | 0,94317 | 287 680,83 | 88,38 | 0,94317 |
| | | 2026 | 299 188,06 | 91,92 | 0,98904 | 299 188,06 | 91,92 | 0,98904 |
| | | 2027 | 311 155,58 | 95,59 | 1,02014 | 311 155,58 | 95,59 | 1,02014 |
| | | 2028 | 323 601,80 | 99,42 | 1,06094 | 323 601,80 | 99,42 | 1,06094 |
| | | 2029 | 336 545,88 | 103,39 | 1,10338 | 336 545,88 | 103,39 | 1,10338 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.11.2024 № 314-2/э-2024
карарына 2 нче кушымта

Үзенә карата электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе өчен
2025-2029 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының исеме | Ел | Контрольдәге чыгымнар-ның база дәрәҗәсе | Контрольдә тотылырга тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Активлар саны буенча контрольдәге чыгымнарның сыгылмалылык коэффициенты | Электр челтәрләре аша тапшырганда электр энергиясен югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача дәвамлылыгы күрсәткече | Электр энергиясен тапшыруны туктатуның уртача ешлыгы күрсәткече | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфат дәрәҗәсе күрсәткече |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | млн сум | % | % | % | сәгать | данә | |
| 1 | Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе – Трансэнергоның структур бүлекчәсе – «РТЮ» ААҖ филиалы | 2025 | 68,479 | 1 | 75 | 2,63 | 2,33098 | 0,56439 | 1,15000 |
| | | 2026 | X | 1 | 75 | X | 2,29602 | 0,55592 | 1,13275 |
| | | 2027 | X | 1 | 75 | X | 2,26158 | 0,54759 | 1,11576 |
| | | 2028 | X | 1 | 75 | X | 2,22765 | 0,53937 | 1,09902 |
| | | 2029 | X | 1 | 75 | X | 2,19424 | 0,53128 | 1,08254 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.11.2024 № 314-2/э-2024
карарына 3 нче кушымта

«РТЮ» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясенең 2025-2029 елларга (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) кирәкле тулай кереме

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе – Трансэнергоның структур бүлекчәсе – «РТЮ» ААҖ филиалы | 2025 | 92 497,44 |
| | | 2026 | 96 197,34 |
| | | 2027 | 100 045,23 |
| | | 2028 | 104 047,04 |
| | | 2029 | 108 208,92 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге